**Татарстан Республикасында Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы уңаеннан «Милли киемнәр» фестивален үткәрү турында нигезләмә.**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. "Милли киемнәр» фестивале Саба муниципаль районы территориясендә 2023 нче елның 15 нче апреленнән 10 нче июненә кадәр татар халкының һәм республикабызда яшәүче барлык халыкларның мәдәниятен саклау һәм үсеп килүче буынга милли тәрбия бирү, Татарстан Республикасында Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы уңаеннан үткәрелә. Татарстанда яшәүче һәр халыкның тарихи-мәдәни мирасы бик зур һәм бай. Һәр халыкның үзенә генә хас милли киемнәрендә халыкның рухи дөньясы, милли үзенчәлекләре чагыла. Ата-бабаларыбыз тарафыннан кертелгән гореф-гадәтләр, гасырлар буе югалмый сакланып килгән милли киемнәребез — халыкны милләт итеп берләштерә торган чараларның берсе. Гореф-гадәтләр, йолалар, милли киемнәр халык тормышының, мәдәниятенең аерылгысыз бер өлеше булып тора.

## 2. Максатлары һәм бурычлары.

**2.1.** Фестивальнең бурычлары һәм максатлары:
- әби-бабаларыбыздан килгән милли кием үрнәкләрен, киенү әдәпләрен саклап калу һәм киләчәк буыннарга тапшыру;
- халкыбызның борынгыдан килгән гореф-гадәтләрен, йолаларын, милли киемнәрен киңрәк өйрәнү һәм алар аша яшь буында милли үзаң тәрбияләү;
- милли мәдәниятебезнең традицияләрен торгызу, үсеп килүче буында милли горурлык хисләре тәрбияләү;
- республикабызда яшәүче милләтләр арасында дуслык, үзара хөрмәт хисе тәрбияләү.

## 3. Фестивальне оештыру

**3.1.** Фестивальне оештыру, үткәрү һәм йомгак ясауны түбәндәге оештыру комитетына йөкләргә:

Заһидуллин Рөстәм Фидаил улы- Саба муниципаль районы мәдәният бүлеге начальнигы
Билалова Ләйсән Рәкыйп кызы - Ә.Кәримуллин исемендәге Саба район үзәк китапханәсе директоры, "Ак калфак"Саба җирле бүлекчәсе җитәкчесе

Фестивальнең мәгълүмати ярдәмен Саба районының массакүләм мәгълүмат чаралары аша тормышка ашырырга.

3.**2 Фестивальдә катнашучыларга таләпләр:**

- фестивальдә катнашучыларның яше чикләнмәгән
- республикада яшәүче барлык милләт вәкилләре дә катнаша ала
- фестивальдә катнашучыларның үзләренең милли киемнәрендә булуы шарт
- сәхнә костюмнарына урын бирелми
- һәр кеше “Милли гаилә” яки "Милли кием- милләтемә тугрылык ул!" номинацияләренең берсендә генә катнаша ала
- “Гаиләбез ядкаре” номинациясендә җиңүчеләр шәхси әйберләре белән Саба Сабантуе көнне күргәзмәдә катнашырга тиеш
- барлык катнашучылар 5 июньгә кадәр үзләренең катнашулары турында sabantuy.2023@bk.ru почтасына заявка җибәрергә тиешләр.

3.3. **Фестиваль номинацияләре:**

**- “Гаиләбез ядкаре” -** гаиләдә буыннан- буынга күчеп, кадерле истәлек булып саклanучы киемнәр, баш һәм аяк киемнәре, хатын-кызларның бизәнү әйберләре белән таныштыру. (Киемнең фотосын һәм 1000 символдан артмаган текстны ВКонтактедагы шәхси битенә, #милликиемсаба хештегларын куеп, 1 июньгә кадәр урнаштырырга). Саба Сабантуе мәйданында нәтиҗә ясала, призлы урын алучылар диплом һәм бүләк алачак.

**- “Милли гаилә” -** барлык гаилә әгъзалары да Саба Сабантуй бәйрәменә милли киемнәрдән килгән гаиләләр арасында уздырыла. Берничә буынның (әби, бабай, әти, әни, балалар) милли киемнәрдән булуы хуплана. Саба Сабантуе мәйданында нәтиҗә ясала, призлы урын алучылар диплом һәм бүләк алачак.

**"Милли кием- милләтемә тугрылык ул!" -** үз халкының милли киемнәре белән Саба Сабантуй бәйрәменә килгән барлык кешеләр арасында уздырыла
Әлеге номинациядә нәтиҗәләр яшь төркемнәре буенча ясала:
- 7 яшькә кадәр
- 7 яшьтән 14 яшькә кадәр;
- 14 яшьтән 18 яшькә кадәр
- 18 яшьтән 25 яшькә кадәр
- 25 яшьтән 30 яшькә кадәр
- 30 яшьтән 40 яшькә кадәр;
- 40 яшьтән 50 яшькә кадәр
- 50 яшьтән 70 яшькә кадәр;
- 70 яшьтән һәм аннан да югарырак.

Саба Сабантуе мәйданында нәтиҗә ясала, призлы урын алучылар диплом һәм бүләк алачак.

**3.4. Конкурс үткәрү этаплары:**

1 этап. (2023 елның 15 апреленнән  2023 елның 1 маена  кадәр) конкурсны үткәрү буенча оештыру комитеты булдыру. Конкурс нигезләмәсен авыл мәдәният йортлары, авыл китапханәләре хезмәткәрләренә, район халкына җиткерү. Конкурсны массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту.

2 этап. (2023 нче елның 1 нче майдан алып 5 нче июньгә кадәр). Милли киемнәрне өйрәнү, халыкка җиткерү, аларны әзерләү. Электрон формада мәгълүмат җыю. Оештыру комитеты алган материалларны гомумиләштерү һәм өйрәнү. "Гаиләбез ядкаре" номинациясендә җиңүчеләрне билгеләү.

3 Этап Саба Сабантуе көнне (2023 елның 10 нчы июне) җиңүчеләргә сертификатлар, грамоталар, истәлекле бүләкләр тапшыру. Массакүләм мәгълүмат чараларында конкурс нәтиҗәләрен яктырту.

3.5.  Әлеге Нигезләмә үзгәртелергә яки өстәмәләр кертелергә мөмкин .

## 4. Йомгак ясау һәм җиңүчеләрне бүләкләү

Конкурска йомгак ясау. Җиңүчеләрне Саба Сабантуе  барышында 2023 елның 10 нчы июнендә бүләкләргә.
Барлык сораулар буенча Әбрар Кәримуллин исемендәге район китапханәсенә мөрәҗәгать итәргә.
Адресыбыз: Байлар Сабасы бистәсе, Төзүчеләр урамы, 2 нче йорт.
Телефон: 2-37-35.
Электрон почта: sabantuy.2023@bk.ru

**«Милли киемнәр» фестивалендә катнашу өчен заявка.**

1. ФИО

2.Туган елыгыз, көнегез

3.Эш (уку) урыны

4. Тору урыны

5. Телефон

6 . Фестивальдә катнашасы киемне киеп төшкән фотосурәт.